ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.04.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1017**

Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 45а йорты адресы буенча урнашкан күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиеш дип тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2018 елның 24 мартындагы 10 номерлы карарын, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 23 сентябрендәге 2088 номерлы карары белән билгеләнгән ведомствоара комиссиянең 2018 елның 24 апрелендәге 254 номерлы актын һәм бәяләмәсен, «Артпроект» ҖЧҖ төзелеш конструкциясен тикшерү хисабын исәпкә алып, РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәне раслау турында» 47 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 45а йорты адресы буенча урнашкан күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиеш дип танырга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru ), хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында, «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

-тартып алынган күчемсез милекнең хокук ияләренә;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ;

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин